# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы
Уразай авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**17 ноябрь 2025 ел** **№1**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Азнакай муниципаль районы Уразай авыл җирлеге Уставы нигезендә 2025 елныц 17 нче ноябрендэ түбәндәге сорау буенча узган гражданнар җыен нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенының йомгаклау протоколы төзелде:

«Сез, 2026 елда 1 төркем инвалидлар, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, махсус хәрби операциягә мобилизациялэнгэннэрнен гаилэ эгъзаларыннан тыщ, түләүне бер тапкыр киметеп 2 төркем инвалидлар, 80 яшьтән өлкәнрәк пенсионерлар, күп балалы гаиләләр өчен 200 сум күләмендә, Азнакай муниципаль районы Уразай авыл җирлеге Уразай торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 400 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнэлту белэн килешэсезме:

- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау (урам яктырткычларындагы лампаларны алмаштыру, яктырткычларны сатып алу һәм урнаштыру);
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Садовая,Н.Бэдертдинова урамнары шартнамәсе буенча вак таш сатып алу, төяү, ташу, салу, эшләр өчен түләү);
- торак пункт территориясен төзекләндерү (чүп үләнен чаптыру, чүп җыю, балалар мәйданчыкларын, ял итү зоналарын карап тоту, автомобиль юлын кардан чистарту, трактор өчен роторлы чапкыч сатып алу).

**РИЗА КАРШЫ».**

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия 566 гражданнар жыенында катнашучы теркәлгән, халык җыенында катнашып тавыш биргән гражданнар саны 288 .

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
«РИЗА» позициясе өчен 288, «КАРШЫ» » позициясе өчен 0 гражданнар җыенында катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Азнакай муниципаль районы Уразай _авыл җирлеге Уразай торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләре – гамәлдә (дөрес) дип таныргa.
2. Түбәндәге сораулар буенча карарны кабул ителгән дип таныргa:

«Сез, 2026 елда 1 төркем инвалидлар, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, махсус хәрби операциягә мобилизациялэнгэннэрнен гаилэ әгъзаларыннан тыш, түләүне бер тапкыр киметеп 2 төркем инвалидлар, 80 яшьтән өлкәнрәк пенсионерлар, күп балалы гаиләләр өчен 200 сум күләмендә, Азнакай муниципаль районы Уразай авыл җирлеге Уразай торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 400 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлту белән килешәсезме:

- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау (урам яктырткычларындагы лампаларны алмаштыру, яктырткычларны сатып алу һәм урнаштыру);

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Садовая,Н.Бэдертдинова урамнарына вак таш сатып алу, төяү, ташу, салу, эшләр өчен түләү);

- торак пункт территориясен төзекләндерү (чүп үләнен чаптыру, чүп җыю, балалар мәйданчыкларын, ял итү зоналарын карап тоту, автомобиль юлын кардан чистарту, трактор өчен роторлы чапкыч сатып алу).

3. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 кон эчендә, Уразай авыл җирлеге мәгълүмати стендларында һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Уразай авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

| | | |
|---|---|---|
| Халык җыенында рәислек итүче,<br>Азнакай муниципаль районы<br>Уразай авыл җирлеге башлыгы | (имза) | Д.И.Мутыгуллина<br>(имза расшифровкасы) |